СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.10.2019 № 35/6
На № ________ от ________

# КАРАР

**«Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәшлек буенча үзгәртү инициативасын хуплау хакында**

2019 елның 1 августындагы 32/9 санлы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәшлек буенча үзгәртү инициативасын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 12 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә һәм халык фикерен ачыклау максатында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәшлек буенча (алар составына керүче торак пунктларны башка муниципаль берәмлекләр территорияләренә кертүгә китерми торган) үзгәртү турында инициативаны хупларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Л.Г. Авзаловка йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев